# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**27 ноябрь 2021 ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Мәнәвез авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 27 нояберендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 80 яшьтән өлкән пенсионерлар өчен 400 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Мәнәвез авылы урамнары исемнәре язылган күрсәткечләр, мәгълүмат стендлары сатып алу(әзерләү));
- спорт мәйданчыгы урнаштыру (мини футбол);
- Күмү урыннарын карап тоту (агач кистерү, чүп-чар җыю һәм чыгару, кусторез сатып алу)
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», “Сабантуй”, «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм һәм спорт чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү»);
- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 480 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 254.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 245, «КАРШЫ» позициясе өчен 9 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре–гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 80 яшьтән өлкән пенсионерлар өчен

400 сум күләмендә, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Мәнәвез авылы урамнары исемнәре язылган күрсәткечләр, мәгълүмат стендлары сатып алу(әзерләү));
- спорт мәйданчыгы урнаштыру (мини футбол);
- күмү урыннарын карап тоту (агач кистерү, чүп-чар җыю һәм чыгару, кусторез сатып алу)
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», " Сабантуй", «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү»);
- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,
- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәнәвез авылы, Советская урамы, 1а адресы буенча, Мәнәвез авылы, Советская урамы, 29 йорт каршында, Мәнәвез авылы, Үзәк урамы, 60 йорт каршында урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Хәсәнов